ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.10.2022 г. Заинск № 545

**2023 елга «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә балаларга сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2023 елга расларга:

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә балаларга сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар кушымтасын;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга төзәтү коэффициентын 0,65 күләмендә.

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «24» 10
545 номерлы карары белән
расланган.

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә балаларга сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (бер укучыга елына сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку срогы | дүрт еллык уку срогы | биш еллык уку срогы | җиде еллык уку срогы | иртә профессиональ юнәлеш |
| Музыка сәнгате | шәһәр җире | | | 74 988 | 85 669 | 110 026 |
| Музыка сәнгате | авыл җире | | | 79 714 | 91 055 | 116 878 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җире | | 39 699 | | 35 247 | 84 588 |
| Сынлы сәнгать | авыл җире | | 42 126 | | 37 425 | 89 801 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җире | | | 83 632 | 68 869 | 252 446 |
| Хореография сәнгате | авыл җире | | | 88 953 | 73 250 | 268 494 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җире | | | 35 168 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җире | | | 37 395 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җире | | | 76 896 | 73 832 | 118 624 |
| Фольклор сәнгате | авыл җире | | | 81 803 | 78 547 | 126 162 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җире | 115 796 | | 111 004 | | 182 027 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җире | 123 091 | | 118 014 | | 193 471 |
| Театр сәнгате | шәһәр җире | 59 697 | | 55 573 | 55 492 | 83 712 |
| Театр сәнгате | авыл җире | 63 434 | | 59 063 | 58 977 | 88 859 |

**Эшләр идарәчесе** **Т.А. Лоптова**